Tatar - Изге Язманың - Good-Bad Mind Scriptures

Good Mind Scriptures

Руттан 1:18 Нагомия, киленененең үз дигәнендә нык торуын күреп, аны үгетләүдән туктады.

Марк 5:15 Гайсә янына килделәр, эчендә ђеннәр булган кешенең киенгән һәм акылына килгән хәлдә утыруын күреп, куркып калдылар.

Лүк 8:35 Кешеләр, нәрсә булды икән, дип, шул урынга киттеләр. Алар Гайсә булган ђиргә килеп ђиткәндә, эченнән ђеннәре чыккан кешенең Гайсә янында киенгән һәм акылына килгән хәлдә утыруын күреп, куркып калдылар.

Рәсүлләр 17:11 Мондагы кешеләр, тессалуникәлеләргә караганда киңрәк карашлы иделәр. Алар сүзне бик теләп кабул иттеләр һәм һәр көн, Паул сөйләгән сүзләрнең дөреслеген тикшерү өчен, Изге язманы өйрәнделәр.

Рәсүлләр 20:19 Зур күндәмлек һәм күп күз яшьләре белән, яһүдләрнең явыз ниятләре аркасында килгән сынаулар эчендә Раббыга хезмәт иттем.

Римлыларга 7:25 Мине Раббыбыз Гайсә Мәсих аркылы коткаручы Иеһоваһыга шөкер! Менә мин акылым белән Иеһоваһы канунына, ә кешелек табигатем белән гөнаһ канунына хезмәт итәм.

Римлыларга 8:6 Кешелек табигате буенча уйлау – үлемгә, ә Рух буенча уйлау – тормышка һәм иминлеккә китерә.

Римлыларга 8:27 Йөрәкләрне карап белүче Иеһоваһы исә Рухның фикерен белә, чөнки Изге Рух, Иеһоваһы ихтыяры буенча, изгеләр өчен Аңа ялвара.

Римлыларга 11:34 Раббының уй-фикерләренә кем төшенде? Яки Аңа кем киңәш бирә ала?

Римлыларга 12:2 Бу дөньяның гадәтләренә буйсынып, алар буенча гамәл кылмагыз, моның урынына, зиһенегезнең яңаруы аша, Иеһоваһыга үзегезне үзгәртергә юл куегыз. Шуның белән Иеһоваһының ихтыярын – нәрсәнең яхшы, Аңа яраклы һәм камил икәнен – аныклый алырсыз.

Римлыларга 12:16 Бер-берегез белән килешеп яшәгез; тәкәббер булмагыз, бәлки гади кешеләр белән аралашыгыз; үзегезне акыллыга санамагыз.

Римлыларга 14:5 Берәүләр ниндидер бер көнне башка көннән мөһимрәк дип исәпли, ә башка берәү һәр көнне бертөрле дип саный. Һәркем үз фикерендә нык торсын.

Римлыларга 15:6 Шулай итеп, сез бердәм рәвештә, бер авыздан Раббыбыз Гайсә Мәсихнең Иеһоваһысын һәм Атасын данларсыз.

1 Көринтлеләргә 1:10 Имандашлар, Раббыбыз Гайсә Мәсих исеме белән һәммәгездән ялварып сорыйм: сез барыгыз да бер сүзле булыгыз,

арагызда тμрле бүленешләр булмасын, киресенчә, уй-фикерләрегез бердәм булсын.

1 Көринтлеләргә 2:16 Чμнки Изге язмада язылганча: «Раббыга киңәш бирергә Аныңь уй-фикерләренә кем тμшенгән?» Ә без Мәсихнеңь уй-ниятләрен аңлыйбыз, чμнки аларны безгә Изге Рух ача.

2 Көринтлеләргә 7:7 Аныңь килүе сәбәпле генә түгел, бәлки Титуска күрсәткән ярдәмегез белән юатты. Мине сагынуыгыз, минем μчен тырышуыгыз һәм кμенүегез турында сμйләп, ул мине тагын да күбрәк куандырды.

2 Көринтлеләргә 8:12 Чμнки тырышлык булганда, кемнеңь нәрсәсе булмауга карап түгел, бәлки нәрсәсе булуга карап бүләге кабул ителә. (1 Паралипоменон 28:9)

2 Көринтлеләргә 9:2 чμнки мин тырышлыгыгызны беләм һәм, Ахаядә ярдәм инде үткән елдан бирле үк әзерләнгән дип, македуниялеләр алдында сезнеңь белән мактанам. Сезнеңь тырышлыгыгыз аларны дәртләндерде.

2 Көринтлеләргә 13:11 Ниһаять, имандашлар, сау булыгыз. Камиллеккә омтылыгыз, бер-берегезне рухландырыгыз, бер фикердә булыгыз, тату яшәгез: мәхәббәт һәм иминлек Иеһоваһысы сезнеңь белән булыр.

Эфеслеләргә 4:23 Фикерләү рәвешегез исә яңарырга тиеш,

Филиппуйлыларга 2:2-5 минем шатлыгымны тулыландырыгыз: бер үк фикергә ия булып, бер мәхәббәтне уртаклашып, бер максат һәм бердәм ниятте булыгыз. 3 үзегезгә файда эзләп яки масаеп һичнәрсә эшләмәгез, киресенчә, күндәм булыгыз һәм башкаларны үзегезгә караганда μстен күрегез. 4 Һәркем үзе турында гына түгел, бәлки башкалар хакында да кайгыртсын. 5 Мμгамәләләрегез Мәсих Гайсәнеке кебек булсын.

Филиппуйлыларга 4:2 Әүдия белән Сүнтүхиянеңь икесе дә Раббыныкы булганга күрә бер үк фикердә булуларын үтенәм.

Филиппуйлыларга 4:7 Һәм һәр акылдан μстенрәк булган Иеһоваһы иминлеге сезнеңь йμрәкләрегезне һәм фикерләрегезне Мәсих Гайсәдә саклаячак. (Ишагыйя 26:3)

Көлессәйлеләргә 3:12 Шулай итеп, сез, сμекле изгеләр, Аныңь сайлаганнары буларак, шәфкатьле, яхшы күңелле, күндәм, басынкы, түземле булыгыз.

2 Тессалуникәлеләргә 2:2 ашыгыч фикер йμртеп, акылыгызны югалтмагыз. Раббыныңь кμне ҡитте, дип рух игълан иткән пәйгамбәрлек сүзе дә, яки кемдер әйткән сүз дә, яки янәсе бездән килгән хат та сезне борчымасын.

2 Тимутегә 1:7 Чμнки Иеһоваһы безгә курку рухын түгел, бәлки кμч, мәхәббәт һәм аек фикер йμртү рухын биргән.

Титуска 2:6 Шул рәвешчә, яшь ир-атларга да тμпле булырга нәсыйхәт бир.

Еврейләргә 8:10 Исраил халкы белән Мин киләчәк кμннәрдә тμзиячәк килешү шушы: үз кануннарымны Мин аларныңь зиһеннәренә салачакмын, күңелләренә язып куячакмын. Мин – аларныңь Иеһоваһысы, ә алар Минем халкым булачак.

1 Петер 1:13 Шуңа күрә, акылыгызны җигеп хәрәкәт итәргә әзер торыгыз, аек акыллы булыгыз, Гайсә Мәсих килгәндә сезгә биреләчәк мәрхәмәткә тулысынча µмет баглагыз.

1 Петер 5:2 үзегездәге Иеһоваһы ышанып тапшырган иман итүчеләр кµтүен мәҗбүриләп түгел, бәлки үзегез теләп һәм Иеһоваһы ихтыяры буенча; акчага комсызланып түгел, бәлки күңел кушканча тырышлык белән кµтегез.

2 Петер 3:1 Иң элек шуны аңлавыгыз кирәк: соңгы кµннәрдә үзләренең нәфес теләкләре буенча гамәл кылучы, мыскыллаучы кешеләр чыгачак.

Ягъкуб 1:17 Һәртµрле игелекле һәм камил бүләк югарыдан, яктылыклар Атасыннан килә. Ул һәрвакыт үзгәрешсез һәм һичкайчан, борылып, караңгылык тудырмый. (Әюбнең 23:13)

Ачылыш 17:9 Монда зирәк акыл кирәк. Һиде баш – хатын утырган җиде тау, шулай ук – җиде патша ул.

Bad Mind Scriptures

Марк 7:21 Фәхешлеккә, урлашуга, кеше үтерүгә, (Хизәкил 38:10)

Лүк 12:29 Шулай итеп, ни ашарбыз, ни эчәрбез дип кайгырмагыз һәм хафаланмагыз.

Рәсүлләр 12:20 Ул Тур һәм Сидун шәһәрләрендә яшәүчеләргә бик ачулы иде. Алар исә, үзара сүз беркетеп, аның янына килделәр һәм, патшаның сарай идарәчесе Бластыны үз якларына аударып, солых сорадылар, чµнки аларның µлкәсе патша µлкәсеннән туена иде.

Рәсүлләр 14:2 Ә иман китермәгән яһүдләр яһүд булмаганнарны иман китергән туганнарына каршы котырттылар.

Римлыларга 1:28 Шулай итеп, Иеһоваһы турында белүне истә тотуны мµһим дип исәпләмәгән µчен, Иеһоваһы аларны, эшләнергә тиешле булмаган эшләрен кыла бирсеннәр µчен, бозык акылга дучар итте.

Римлыларга 8:6,7 Кешелек табигате буенча уйлау – үлемгә, ә Рух буенча уйлау – тормышка һәм иминлеккә китерә. 7 Чµнки кешелек табигате буенча фикер йµрткән кеше – Иеһоваһыга дошман; ул Иеһоваһы канунына буйсынмый һәм буйсына да алмый.

Римлыларга 11:20 Дµрес. Алар иман итмәгәнгә сындырылдылар, ә син иман итүең белән урыныңда торасың; борыныңны күтәрмә, киресенчә, сак бул!

2 Көринтлеләргә 10:5 Иеһоваһыны танып белүгә каршы тәкәббер рәвештә калыккан һәртµрле комачаулыкларны җимерәбез һәм Мәсихкә итагатьле итү µчен һәр фикерне үзебезгә буйсындырабыз

2 Көринтлеләргә 11:3 Әмма шуннан куркам: елан Хауваны үзенең хәйләсе

белән алдаган кебек, Мәсихкә карата ихлас күңелдән булган сафлыктан читкә тайпылып, фикерләрегез чуалып китмәсен иде.

Эфеслеләргә 2:3 Кайчандыр барыбыз да алар кебек тәнебез һәм фикерләребезнең теләкләре буенча табигатебезнең теләкләрен үтәп яшәдек. Без дә, калган башкалар кебек үк, табигый хәлебез буенча Иеһоваһыныңкаһәрен алырга тиеш идек.

Эфеслеләргә 4:17/18 Шуңа күрә, Раббы исеменнән катгый рәвештә кисәтәм: тормышыгызны буш уйлы мәҗүсиләр кебек дәвам итмәгез. үзсүзле булганга күрә, алар белергә дә теләмиләр, шунлыктан акыллары чуалган һәм алар Иеһоваһы бирә торган тормыштан аерылганнар.

Көлессәйлеләргә 1:21 Һәм сезне, фикерегез һәм яман эшләрегез аркасында элегрәк Иеһоваһыга чит һәм дошман булганнарны, (Кинаяләр 21:27; Хизәкил 23:17)

Көлессәйлеләргә 2:18 Ясалма тыйнаклыктан һәм фәрештәләргә табынудан ләззәт табучы һичкем сезне савап алу хокукыннан мәхрүм итмәсен. Андый кеше үзе күргәннәр белән горурлана, кешелек акылының буш уйлары аны масаючан итә.

1 Тессалуникәлеләргә 5:14 Без сездән, туганнар, үтенеп сорыйбыз: эшсез утыручыларны үгетләгез, курка торганнарны дәртләндерегез, хәлсезләргә ярдәм итегез. Бар кешеләргә карата түземле булыгыз.

2 Тессалуникәлеләргә 2:2 ашыгыч фикер йөртеп, акылыгызны югалтмагыз. Раббының күне һитте, дип рух игълан иткән пәйгамбәрлек сүзе дә, яки кемдер әйткән сүз дә, яки янәсе бездән килгән хат та сезне борчымасын.

1 Тимутегә 6:5 акылларына зыян килгән һәм хакыйкатьтән мәхрүм калган кешеләр арасында фикер каршылыклары туа. Шул кешеләр, диндарлык табыш казануга хезмәт итә, дип уйлыйлар. Андыйлардан ерак йөр.

2 Тимутегә 3:8 Янис һәм Ямбрис Мусага каршы килгән кебек, бозык акыллы һәм иманда файдасыз булган бу кешеләр шулай ук хакыйкатькә каршы киләләр.

Титуска 1:15 Сафлар өчен барысы да саф, әмма бозык һәм имансыз кешеләр өчен бернинди саф нәрсә юк, чөнки аларның акыллары һәм вөҗданнары бозык.

Еврейләргә 12:3 Гөнаһлылар тарафыннан шундый каршылыкны кичергән Гайсә турында уйлагыз; бу күңелегезне төшермәскә һәм Иеһоваһыга ышанудан туктамаска ярдәм итәр.

Ягъкуб 1:8 Мондый кеше – икеләнүчән, үзенең кылган гамәлләрендә нык тормаучан.

Pastor T. John Franklin
Church of Salvation, Healing, and Deliverance
COS-HAD.org